БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
24 август 2020 ел

**КАРАР**
№ 261

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданы» исеме турында Нигезләмәгә һәм комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен бирү турында тәкъдимнәрне карау буенча комиссия карарын карап, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен бирү турында тәкъдимнәрне карау буенча комиссия составындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2010 елның 2 апрелендәге 178 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданы» исеме турында Нигезләмәгә (2009 елның 31 маендагы 192 номерлы соңгы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Гомуми нигезләмәләр» бүлегенең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Мактаулы граждан исеме Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы тарафыннан «Сабантуй» район милли бәйрәмен яисә Татарстан Республикасы көненә, Балтач районы төзелүнең юбилей даталарына багышланган тантаналы район чараларын уздырганда тапшырыла».

2. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Мактаулы гражданы» исемен бирү турында тәкъдимнәрне карау комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Комиссия составына кертергә:

- Мөхәммәтшина Алсу Илдар кызы - ТР Балтач район Советының җирле үзидарә органнары белән эшләү бүлеге башлыгы, комиссия секретаре.

2.2. Комиссия составыннан төшереп калдырырга:

- Хәйруллина Розалия Нигъмәтулла кызы.

3. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин